**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“18” ноябрь 2023 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегенең Югары Сәрдә торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылы территориясендә 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегенең Югары Сәрдә авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән контракт төзгән хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаиләсе әгъзаларынан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Югары Сәрдә авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачларны кисү һәм куаклар, үлән чабу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Урам яктыртуына хезмәт күрсәтү (яктырткычлар сатып алу);

3) Югары Сәрдә авыллы зираты территориясен төзекләндерү һәм чистарту агач һәм куакларны кисү, чистарту; (агачларны кисү һәм куаклар, үлән чабу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) Алмяш, Тургай, Яшеллек урамнары буенча Югары Сәрдә авылы урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, урам юлларын ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегенең Югары Сәрдә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Югары Сәрдә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы Хуснутдинов Р.Р.